Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы муниципаль бюджет
гомуми белем учреждениесе “Гаделша урта гомуми белем мәктәбе”

# Математика дәресләрендә проект эшчәнлеген куллану

Башкарды:
математика укытучысы
Хусаинова А.Р.

Математика дәресләрендә проект эшчәнлеген куллану

Хәзерге заманда проект сүзе бик популяр. Бу сүзне без газета-журнал битләреннән еш укыйбыз, телевидение аша төрле проектлар карыйбыз. Шулай ук проект сүзе мәктәп кысаларында да еш кулланыла.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле юнәлешләреннән берсе булып проектлар методы санала.

Укытучы элеге методны кулланып, укучының иҗади потенциалын тулысынча ачарга, фантазиясен, активлыгын, мөстәкыйльлеген, тикшеренү-эзләнү сәләтләрен күрсәтергә мөмкинлек тудыра. Проект эшчәнлеген дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек барышында да кулланып була.

Проект эшчәнлегенең төп максатлары:

1. Укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачу.
2. Уку укыту гамәлләрен формалаштыру.
3. Сәбәп – нәтиҗә бәйләнешләрен табу.
4. Укучыларның эзләнү, чыгыш ясау, төркемдә эшләү күнекмәләрен үстерү.

Формасы буенча проект берничә төргә буленә: шәхси проектлар, төркем проектлары һәм парлы проект. Проектның нәтиҗәсен репортаж, реферат, эзләнү-тикшеренү эше, презентация, фото коллаж рәвешендә ясап була.

Проектлар өстендә эшне оештырганда түбәндәгеләрне истә тотарга кирәк:

- Проектның темасы (проблемасы) актуаль һәм башкаларда кызыксыну уятырлык булырга тиеш.
- Проект өстендә эшләүгә мөмкин кадәр күбрәк укучыны тартырга, һәркемгә белем дәрәҗәсен исәпкә алып биремнәр бүлеп бирергә. Бу күпкырлы мәгълүмат җыярга мөмкинлек бирә.

Югарыдагылардан чыгып проект өстендә эшне берничә этапка бүлеп карап була:

1. Әзерлек этабы: проектның темасын, максатын һәм проблемасын билгеләү.
2. Эшчәнлекне планлаштыру һәм проблемаларны чишү этабы.
3. Мәгълүмат эзләү, туплау. Җыелган мәгълүмат арасында бәйләнешне билгеләү.
4. Мәглүматне гомүмиләштерү, системага салу.
5. Нәтиҗәләр чыгару (реферат, презентация, доклад, газета һ.б.)
6. Эшчәнлек нәтиҗәләрен анализлау.

Укучыларның проект эшчәнлеген оештыру җиңелләрдән түгел: укучыны кызыксындыру, аның өчен кызыксындырырлык тема тәкъдим итү, укучыларга кирәкле фәнни әдәбият сайларга ярдәм итү, китап белән эшләргә өйрәтү, тема буенча интернет материалларына күзәтү ясау мөһим. Дөрес оештырылганда бу эш үз гыйлемнәрен камилләштерергә омтылган укучыларга иҗади мөмкинлекләрен үстерергә, фәнни эшне оештыруда беренче практик күнекмәләр формалаштырырга, профессиональ юнәлеш бирүнең эчтәлеген баетырга мөмкинлек бирә. Укытучының төп максаты – проблемага кызыксыну уяту, бары тик шул вакытта гына проект эше максатка юнәлешле була, ә уку материалын үзләштерү аңлап укуга китерә, укучылар эшчәнлеге танып-белү күнекмәләрен үстерә.

Проект эше үзәгендә укучы тора. Бу эштә катнашу укучылардан да күпне таләп итә. Укучы мөстәкыйль эшләү күнекмәсенә ия булырга – кирәкле мәглүматны туплый, өстәмә материаллардан файдалана, компьютер технологияләрен куллана, үз эшен планлаштыра, әңгәмә кора, карарлар кабул итә, эзләнә, эшнең нәтиҗәсен бәяли, үз фикерен әйтә алырга тиеш. Проект эше укучыларда үз эшенә, коллектив эшенә җаваплылык хисе, тапшырылган эшне ахырына җиткерү сәләте тәрбияли.

Урта сыйныф укучылары арасында кызыксынуларына нигезләнеп, төрле типтагы проектлар эшләргә мөмкин: тикшеренү, иҗади, мәглүмати һәм социаль.

Математика дәресләрендә иҗади проект эшчәнлеген отышлы итеп файдаланырга мөмкин. Зур бүлеккә кереш дәресне үткәргән көнне укучыларга өйрәнеләсе тема буенча иҗади эшләр тематикасын тәкъдим итеп, йомгаклау дәресендә әлеге проектларны яклау мөмкинлеге тудыру.

5-6 сыйныф укучылары зур кызыксыну белән иҗади проектлар башкаралар. Мәсәлән, “Безнең тормышта процент”, “Бөек ватан сугышы саннарда”, “Борынгы озынлык үлчәү берәмлекләре”, “Координаталар яссылыгында астрология” һ.б. темалар буенча төзелгән проект эшләре бик уңышлы килеп чыкты.

Геометрия курсын өйрәнгәндә фәнара проект төрен кулланырга мөмкин. “Төзек күппочмаклар” темасын өйрәнгәндә укучылар “Төзек күпкырлыклар” дигән проект төзеделәр. Бу проект геометриянең биология, физика фәннәре белән бәйле булуын нигезләде.

Азкомплектлы мәктәптә эшләгәнгә күрә, мин укучыларга парлы яки төркем белән башкарыла торган проект төрен тәкъдим итәм.

Проект эшчәнлеген кулланганда түбәндәге киңәшләрне истән чыгармаска кирәк:

- Эшне оештыруга иҗади якын килү.
- Укучыларның фикер - тәкъдимнәрен исәпкә алу.
- Укучылар мөстәкыйльлеген мактау, турыдан-туры күрсәтмәләр бирмәү.
- Предметара бәйләнешләрне ачыкларга өйрәтү.
- Укучы үзе генә дә булдыра алган очракларда ярдәм итүдән саклану.
- Укучыларда анализ, синтез, гомумиләштерү күнекмәләре формалаштырырга тырышу.

Математика дәресләрендә проект эшен файдалану – укучыларның танып – белү эшчәнлеген таган да нәтиҗәлерәк оештыру мөмкинлеге бирә.

Бу исә аларның активлыгын һәи зирәклеген, иҗади сәләтен устерергә ярдәм итә.